| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| С О В Е Т<br>Нижнекамского муниципального района | Түбән Кама муниципаль районы<br>С О В Е Т Ы |
| 423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12<br>факс (8555) 43-15-35, тел.42-41-41 | 423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12<br>факс (8555) 43-15-35, тел.42-41-41 |


Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

№ 60 27 сентября 2021 года

## Түбән Кама муниципаль район Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 23.1 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 сентябрендәге 48 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 4 нче кушымтаның һәм 16 нчы кушымтаның 3 пунктларында «социаль характердагы түләүгә керә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Түбән Кама муниципаль район Советының 2021 елның 1 сентябрендәге «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Түбән Кама муниципаль районы бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында» 49 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

таблицаның беренче юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Оешма җитәкчесе | 2,25 |

таблицаның икенче юлында «оешмалар» сүзен төшереп калдырырга.

3. Түбән Кама муниципаль район Советының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, Түбән Кама муниципаль районы җирле үзидарә органнарына әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

5. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль район Советының социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы

А.Р.Метшин